**/ Чал тарихта эзле без! /**

## *Әрәмә*

Түбән Майна авылы эченә култык булып кереп торган Чирмешән елгасының тугае халык телендә **"Әрәмә"** дип атала. Исеменнән күренгәнчә, бу урында элек әрәмәлек, ягъни куаклык булган. Авылның XVIII гасыр ахырына караган планында Әрәмә куаклар каплап торган сазлык итеп күрсәтелгән. Аның куаклыгы Чирмешән ярлары буйлап сузылып, бер яктан Тирмән алдындагы, икенче яктан Шалканаттагы урманнарга тоташкан булган. Шулай итеп Чирмешән елгасы Шалканаттан Олы күпергә чаклы тоташ куаклык эченнән аккан. XIX гасыр уртасында Әрәмәнең куаклыклары хәзерге мәчет артында гына калган. XIX гасыр ахырларында аның көнчыгыш өлешендә Насыйр һәм Сафиулла бабайларның умарталары торган. 1960-1970 нче елларда Әрәмәдә колхозның яшелчә бакчасы булдырыла. Шул сәбәпле, бу җирне кайвакыт **"Яшелчә"** дип тә атыйлар. Хәзерге вакытта Әрәмә җәй көннәрендә яшь терлекләрне ябып тору урыны буларак файдаланыла.




***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/ Безнең спорт /**



Шахмат уен төре безнә ел дәвамында үзенә бертөрле киеренке халәттә тотты. Һәрдаим бу спорт төренең турнирлары, аларның нәтиҗәләре турында хәбәрдар булып бардык. 9 - 12 декабрь көннәрендә Татарстан Республикасының Баулы шәһәрендә турнирлар сериясенә йомгак ясаучы **"Кама аръягы Гран-при шахматлар турнирының XVI сериясе"** шахмат уеннары үтте. Безнең мәктәпнен 5 сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** "АЛТЫН ФИЛ" номинациясендә **I урынга** лаек булып, кубок һәм акчалата приз белән бүләкләнде.

18 нче декабрьдә Норлат шәһәрендә **милли көрәш** буенча Туган телләр елына багышланган ачык беренчелек булып узды. Безнең мәктәптән бу ярышта катнашкан 10 сыйныф укучысы **Камалов Илдус – I**, 6 сыйныф укучысы **Шичкин Али – III**, 3 сыйныф укучысы **Хәбибрахманов Абдулла – III урыннарга лаек** булдылар. Али өчен бу уен әле дебют кына булуга карамастан, беренче тапкыр урын алуга да китерде.



23 нче декабрь көнне безнең көрәшчеләр даими катнашып килгән Норлат районының "Чулпан көрәш мәктәбе" призына **билбау көрәше** буенча беренчелек уздырылды. Бездән бу ярышта катнашкан 8 сыйныф укучысы **Галимов Рияз III урынны** алды.

26 нчы декабрьдә Чистай шәһәренең "Батыр" спорт мәктәбе Кыш бабай призына **милли көрәш** буенча турнир үткәрде. Бу бәйгедә безнең мәктәптән катнашкан 3 сыйныф укучылары **Җамалетдинов Зөлфәт** белән **Донсков Артур** икесе дә **III урыннарга** ия булдылар.

Спортчы егетләребезне һәм аларның остазлары **Камалов Ильһам абыйны** уңышлары белән котлап, киләчәктә дә яңа җиңүләргә ирешүләрен телибез!

**/ Котлыйбыз! /**



Декабрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз – бакча тәркеменнән **Гафиятуллина Руфинәне** һәм 9 сыйныфтан **Әхсәнов Халитны** туган көннәре белән котлыйбыз! Аларга укуларында уңышлар, сәламәтлек, тырышлык телибез!

Күп еллар буе балаларга рус теле һәм әдәбиятыннан белем бирүче, яраткан укытучыбыз **Нәҗметдинова Раушания апаны**, техник хезмәткәр **Хәтметдинова Рәхилә апаны** юбилейлары белән ихластан тәбрик итәбез. Аларга сәламәт озын гомер, гаилә тигезлеге, балалары һәм оныкларының шатлыгын күреп яшәүләрен телибез. Тәрбияче **Яхина Рузилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлыйбыз. Сезгә алдагы тормышыгызда гел шатлык-сөенечләр генә юлдаш булсын.


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәмматова
Зөлфирә Сафиуллина



# Мәктәп хәбәрчесе

**№10** (№31) декабрь 2021 ел

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


## *Якынлашып килүче 2022 нче ел белән дуслар!*



*Кадерле дуслар!*

*Барыгызны да Яңа 2022 нче ел белән тәбрик итәбез. Алдагы ел барчабызга да уңышлар гына китерсен. Һәркемнең хыялы тормышка ашсын. Иминлек, сәламәтлек, муллык, укуда тырышлык безнең белән гел янәшә атласын!*

*"Мәктәп хәбәрчесе"редколлегиясе*

**/ Мөгаллим минбәре /**

## Функциональ белемлелек

Гомуми белем бирү системасында һәрвакыт яңалыклар өстәлеп тора. Аларга тормышта кирәкле булачак белемне, мәгълүматны бирү генә түгел, куллана белүне дә максат итеп куя торган алымнар бар. Шуларның берсе – укучыларда функциональ белемлелекне формалаштыру. Нидән гыйбарәт икән соң бу алым?

**Функциональ белемлелек (функциональная грамотность)** – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул. Аның төп юнәлешләре уку, математика, табигый фәннәр, чит телләр, компьютер, финанслар буенча белемлелекне һәм аралашу белән креатив фикерләүне үз эченә ала.

Туган тел укытучысы буларак, уку белемлелегенә тирәнрәк тукталасым килә. Чөнки ата-аналарның һәм укытучылар күтәргән төп сорауларның берсе – «безнең балалар укый белми», «укыганнарын аңламыйлар», «бала калын китап укыды, ләкин аның турында берни дә сөйли алмый». Димәк, уку күнекмәләре һәм укый белү — икесе ике нәрсә булып чыга. Функциональ белемлелек — иң беренче чиратта мәгълүмат белән эшли белү дигәнне аңлата. Белем бирүнең нинди генә предмет өлкәсен алсак та, беренче чиратта, аңлап уку, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аера белү сәләте кирәк. Укытучыларга дәресләрдә бу максаттан чыгып, төрле алым һәм формаларга таянырга туры килә. Төп максатларның берсе – укучыларның алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтү. Уку белемлелеген формалаштыруда текст белән эшли белүгә игътибар итәргә кирәк, чөнки текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст, кагыйдә, формулалар, терминнарны практикада кулланырлык итеп өйрәнүнең роле зур. Башлангыч сыйныфларда тиз укырга өйрәнү – функциональ грамоталылыкның нигезе булып тора. Чөнки бала акрын укый икән, ул иптәшләре алган кадәр белемне үзләштерергә өлгерми, фикерләү тизлеге дә кими. Бу үз чиратында баланың укуга сәләтен тагын киметәчәк һәм фәннәр арасындагы чылбыр өзелергә мөмкин.

Үземнең тәҗрибәдән чыгып, дәрестә текст белән эшләүне укучыларга кызыклы да, аңлаешлы да булырлык итеп оештырырга кирәк дип саныйм. Язма текстлар белән эшләгәндә түбәндәге эш алымнарын кулланам:

- текстның исеменә игътибар итү, «Ни өчен текст шулай атала?» соравына җавап эзләү, темасын билгеләү;
- төп төшенчәләрне аерып алу һәм язып кую;
- тексттан ачык бирелгән мәгълүматны яки фактларны таба белү, аларны тормышчан мисаллар белән ныгыту;
- текстны кисәкләргә бүлү, планын төзү, төп вакыйгаларны аерып алу;
- тәкъдим ителгән рәсем һәм иллюстрацияләрнең текстның кайсы өлешен ачу өчен кулланылуын әйтү;
- текст нигезендә зур булмаган монологик яки диалогик сөйләм төзү, эчтәлек буенча үзара сораулар бирешү.

Дәрестә генә түгел, дәрестән тыш чараларда да текст белән эшләүнең мөмкинлекләре күп.

**Тәнкыйди фикерләү (критическое мышление) технологиясе** элементларын куллану укучыларда уку грамоталылыгын формалаштыруның өстенлекле бер алымы булып тора. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак. Килеп туган мәсьәләне дөрес чишү юлларын табу, күпсанлы мәгълүмат белән эшләү, анализлау шуңардан башка мөмкин түгел.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, укучыларның функциональ белемлелеген үстерү – һәр укытучының да төп бурычы булырга тиеш. Шуңардан башка яшь буынны хәзерге заман шартларында үзен иркен тота алырлык итеп тәрбияләү мөмкин түгел.

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## Яртыеллык эш нәтиҗәләре

**/ Рәсми хәбәрләр /**

28 декабрь көнне 2021-2022 нче уку елының беренче яртыеллыгы тәгәлләнде. Икенче чирек нәтиҗәләре буенча мәктәп күләмендә белем сыйфаты 59% тәшкил итте. Яртыеллыкны 4 укучы: IV сыйныфтан Закирова Ләйсән, V сыйныфтан Гафиятуллин Фаил, X сыйныфтан Сафиуллина Зөлфирә белән Туктамышева Әминә гел "5"ле билгеләренә генә тәмамлады."4"ле, "5"ле билгеләренә 22 укучы өлгерде.

Бу чиректә фән олимпиадаларының район туры булып узды. Нәтиҗәләр түбәндәге таблицада китерелә:

| Фән | Сыйныф | Укучы | Урын | Укытучы |
|---|---|---|---|---|
| Математика | V | Гафиятуллин Фаил | III | Зарипов Фәнил Закир улы |
| Татар теле | IV | Закирова Ләйсән | I | Камалова Сирень Равил кызы |
| | V | Залиева Вәсилә | I | Гафиятуллина Фәнүзә Госман кызы |
| | X | Туктамышева Әминә | I | |
| Татар әдәбияты | VIII | Гафиятуллин Самат | I | |
| | X | Туктамышева Әминә | I | |
| Рус теле | X | Туктамышева Әминә | I | Кадырова Гөлнур Габделхак кызы |
| Рус әдәбияты | XI | Насыйрова Сара | I | Нәҗметдинова Раушания Рөстәм кызы |

Закирова Ләйсән, Гафиятуллин Самат, Туктамышева Әминә, Насыйрова Сара олимпиадаларның республика турында катнашырга тиешләр. Кышкы каникуллар 29 нчы декабрьдән 11 нче гыйнварга кадәр дәвам итәчәк.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту буенча директор урынбасары.***

**/ Мәктәп тормышы /**

## Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын йомгакладык



2021 ел Татарстанда "Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы" буларак узды. Әйтергә кирәк, татар мәктәбе буларак, безнең өчен һәр ел Туган тел, Милли мәдәният елы булып тора. Чөнки безнең төп максат – авылыбызда милли мәгариф учагын саклау һәм үстерү. Шуңа да карамастан, узган ел милли эчтәлекле чараларга аеруча бай булды. **Төрле кичәләр, күренекле шәхесләр белән очрашулар, сәяхәтләр, балалар Сабан туе һәм башка бәйрәмнәр** – барысы да бик матур һәм истә калырлык итеп узды. **Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы мәктәбебезгә матди яктан да зур файда китерде.** Ярты миллион сумлык грант отып компьютерлар, видеопроекторлар һәм башка техник җиһазлар алу, Мәгариф министрлыгы биргән интерактив такта, спонсорлар бүләк иткән мини-типография – болар барысы да Туган телләр елы нәтиҗәсе.

Инде менә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына йомгак ясар вакыт та җитте. Шул уңайдан 21 нче декабрь көнне мәктәптә кичә уздырылды. Укучылар туган телгә багышланган шигырьләр сөйләделәр. Телебез турында җырлар, милли биюләребезне башкардылар. "Оста куллар" түгәрәгенә йөрүчеләр үзләренең кул эшләнмәләреннән әзерләнгән күргәзмә белән таныштырдылар. Кичәдә Түбән Майна һәм Иске Әдәм авылларының китапханәчеләре Яхина Рузилә һәм Тагирова Равия апалар да катнашты. Алар укучыларга үзебезнең якташ язучыларыбыз турында бик үтемле һәм мавыктыргыч итеп чыгыш ясадылар.




Бәйрәмнең иң күңелле өлеше **милли эчтәлекле интерактив уеннар** булгандыр. Әлеге уеннар безгә Туган телләр елы алып килгән интерактив тактада уйналды. Чара ахырында төрле конкурсларда җиңүче укучылар грамоталар белән бүләкләнде. Бәйрәм, мәктәптәге башка зур чаралар кебек үк, кумәкләшеп "Туган тел" җырын башкару белән тәгәлләнде.

Туган телебез саклану дәрәҗәсендә генә калмыйча, яшәешебезнең аерылгысыз өлеше, төп аралашу чарасы булып калсын иде. Мәктәптә чәчелгән милли тәрбия орлыклары, укучыларыбызның күңелләренә үтеп, **милли узаң** һәм **көчле татар рухы** булып шытып чыксыннар иде.

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары.***

## Тылсымлы Яңа ел бәйрәме

**/ Безнең бәйрәмнәр /**



Уку елы дәвамында бәйрәмнәр күп булса да, иң мавыктыргычы, тылсымлы бәйрәм – Яңа елны каршы алу тамашасыдыр. Яңа ел бәйрәмен өлкәннәр дә, балалар да сагынып көтеп алалар. Ул бала чакны искә төшерә, ямь-яшел бөдрә чыршы, кәгазьдән ясалган кар бөртекләре, ялтыравыклы шарлар белән хәтергә уелып кала. Шуңа да бу кичәне күңелле һәм истә калырлык итү өчен, укытучылар һәм өлкән сыйныф укучылары елдан-ел төрләндерәп, яңалыклар кертеп әзерлиләр.

Быелгы Яңа ел бәйрәмнәре мәктәптә 28 декабрь көнне уздырылды. Шул көннең иртәсендә балалар бакчасына йөрүчеләр һәм I-VI сыйныф укучылары зал уртасындагы матур итеп бизәлгән чыршы тирәсенә җыелдылар. Бәйрәмне башлар алдыннан уку елының беренче яртысына нәтиҗәләр ясалды. Уку алдынгыларын, олимпиадада, конкурсларда җиңүчеләрне котлап, мәктәп директоры Рафик абый дипломнар тапшырды. Икенче өлештә инде җыр-биюләр һәр кунакны ял иттерерлек итеп әзерләнгән иде. Кыш Бабай белән Кар Кызы да ихластан уйнадылар. Башлангыч сыйныф укучыларының биюләре бигрәкләр дә тамашачылар күңеленә хуш килде.

Бәйрәм тамашасы барышында призлы уеннар уйнатылды. Катнашучыларны, күргәзмәгә конкурс эшләрен тапшыручылар укытучы апалары әзерләгән бүләкләрне алдылар. Балаларның кул эшләнмәләре елдан-ел матуррак ясала. Аларны килгән кунаклар да исләре китеп карый. Бу эшләрне алар, әлбәттә инде, әти-әниләр һәм апа-абыйлары белән берлектә ясаган. Шулай булуы да куандыра, чөнки өлкәннәр игътибары баланы тагын үсендерә. Яңа ел бәйрәменең беренче өлеше районыбыз башлыгы Гилманов Камил Камал улы тарафыннан җибәрелгән татлы бүләкләр өләшү белән тәгәлләнде.

Өлкән сыйныфлар өчен Яңа ел бәйрәме мул итеп әзерләнгән табыннар артында уза. Чәй эчүләр укучыларның чыгышлары белән чиратлашып үрелеп бара. Шунысы куанычлы, кызыклы номерлары әзерләүдә дусларыбыз үзләренең осталыкларын арттыра баралар.

Яңа ел бәйрәмнәре анда катнашкан һәркемгә ошагандыр дап уйлыйм. Шулай булмаса истәлеккә төшкән фоторәсемнәр дә елмаючы һәм шатлыклы йөзләрдән тормас иде. Язмамның ахырында барлык иптәшләремә, укытучыларга Яңа елда саулык-сәламәтлек һәм уңышлар теләп калам. Бәйрәмне оештыручыларга, табынга тәмле ризыклар пешерүчеләргә дә рәхмәтемне җиткерәм.

***Рузилә Мөхәммәтова, 11 нче сыйныф укучысы***

**/ Укучылар иҗаты /**

### *Буранлы кыш*

Ап-ак карлы буранлы,
Саф һавалы кыш җитте.
Бөтен җирдә кар көртләре,
Бигрәк матур, ис китте.

Тәрәзәдән карап торам,
Урамда көчле буран.
Ярый әле өйдәмен дип,
Эчтән шатланып куям.

Без бураннан курыкмыйбыз
Каршылыйбыз бик зурлап.
Яратабыз курсәтсә дә
Кар-буран безгә дулап.

***Мәрьям Вәлиева,***
***5 нче сыйныф укучысы.***

-------------------------------------

### *Кыш*

Тәрәзәдән карап,
Кышка хозурланам.
Үзем мин шулай
Җанга рәхәт алам.

Кышның аның рәхәт
Салкыны, һавасы.
Шыгырдаган кары,
Җәяүле бураны.

Яратам мин кышны,
Һәрчак көтеп алам
Тизрәк җитсен диеп,
Көннәр санап торам.

***Фаил Гафиятуллин,***
***5 нче сыйныф укучысы***

## *Пушкин картасы*
## *"Яктылыкка, нурга илтә"*



Белгәнегезчә, быелгы уку елы башыннан "Пушкин картасы" программасы гамәлгә керде. Безнең укучылар аны теләп файдалана башлады. Бу программа буенча безнең районда да берничә чара үткәрелде. Аларны читтән килгән иҗат төркемнәре дә, районның мәдәният оешмалары да уздыра. Шундый чаралардан безнең мәктәп укучылары узган айда Яңа ел тамашасында катнаштылар.

Ай ахырында Аксубай мәдәният йорты укучылар өчен "Яңа ел" тамашасы оештырды. Барыбыз да бик теләп заманча итеп уйланган, яшь үзенчәлекләренә туры килгән уеннарда, төрле конкурсларда катнаштык. Тамаша ахырында һәр катнашучыга Кыш Бабайдан бүләк тапшырылды.

***Әминә Туктамышева, 10 сыйныф укучысы***